БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 12 2020 ел № 384

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләмнәре турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын, «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез тукландыруны оештыру һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 елның 6 октябрендәге 908 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: 2021 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 7 сум 70 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар ризык белән тукландыруны оештырырга.

2. Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучылар өчен 2021елның 11 гыйнварыннан һәр уку көненә 53 сум 41 тиен күләмендә түләүсез туклануны оештырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм Татарстан Республикасы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов